СОВЕТ ШАДЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.18, с. Шадчи,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422145

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘДЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Яшьләр ур., 18 нче йорт, Шәдче авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422145

тел.(факс): (85563) 2-52-24; e-mail: Shad.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

17 сентябрь 2018 ел. **№6-37**

**Референдум уздыру инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Жирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Шәдче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге Советы К А Р А Р КАБУЛ ИТТЕ:

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2019 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

**1.Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмиятле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру;**

- Шәдче т.п. (М. Җәлил ур.), Яңа Мочалкино т.п. зиратына, Иске Мочалкино т.п. зиратына грунт өслеге белән капланган юлларны ремонтлау;
- Шәдче, Вахит, Иске Мочалкино, Яңа Мочалкино, Юкәче, Ямаш, Тәкәрлек авылларында юлларны кардан чистарту.

**2.Җирлекнең торак пунктларын янгын куркынычсызлыгының төп чаралары белән тәэмин итү:**

- Шәдче т.п., Вахит т.п., Юкәче т.п., Ямаш т.п. янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру.

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге башлыгы В.В.Шрыковка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Шәдче авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе Шрыков В.В.